**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.05.2017 № 536

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу планнарын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 05.04.2013 ел, №44-ФЗ Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 21 ноябрендәге 1043 номерлы «Россия Федерациясе субъекты һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу планнарын формалаштыру, раслау һәм алып бару таләпләре, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу планнары формасына таләпләр турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ: 1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу планнарын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибен (1 нче кушымта) расларга. 2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында " Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга. 3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары И.А. Леоновка йөкләргә.

Җитәкче А.А.Насыров